**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**29 март 2019 ел** **№214**

**Нурлат муниципаль районы Советының «Нурлат муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында Нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 13 июлендәге 158 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законнар, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1.Нурлат муниципаль районы Советының 2018 елның 13 июлендәге 158 номерлы карары белән расланган Нурлат муниципаль районында хезмәт (вазыйфаи) тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссия турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең «Муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәүгә һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салуга кагылышлы мәсьәләләрне комиссия тарафыннан карау тәртибе» Зөлешен киләсе эчтәлектәге 3.2.6 пункты белән тулыландырырга:

«3.2.6. Әлеге Нигезләмәнең 3.2.1, 3.2.3 һәм 3.2.4 пунктларында каралган дәлилләнгән бәяләмәләрдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

а) әлеге нигезләмәнең 3.1. пункты "д" пунктчасында һәм "б" пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдә яисә белдерүләрдә бәян ителгән мәгълүмат;

б) дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан һәм кызыксынган оешмалардан мөрәҗәгатьләр нигезендә алынган мәгълүмат;

в) әлеге Нигезләмәнең яки башка карарның 3.9, 3.10.3, 3.11 пунктлары нигезендә карарларның берсен кабул итү өчен, әлеге Нигезләмәнең 3.1 пунктындагы "б" пунктчасының икенче һәм бишенче абзацларында күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрне һәм мөрәҗәгатьләрне алдан карау нәтиҗәләре буенча дәлилләнгән нәтиҗә.»

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталына урнаштырырга.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Нурлат муниципаль районы башлыгы урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Советы рәисе                                                                                    А.С. Әхмәтшин